ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 декабрь 2019ел № 6263

Башкарма комитетның 2018 елның 19 октябрендәге 6260 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ номерлы Законы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 19 октябрендәге 6260 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5.1 пунктка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- әлеге регламентка 4 нче кушымта нигезендә җир законнарын үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү;»;

- түбәндәге эчтәлектәге ундүртенче абзац белән тулыландырырга:

«- Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча, вазыйфаи зат тарафыннан капиталь төзелеш объектын җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән чикләүләре нигезендә мондый

объектны урнаштыру рөхсәт ителми торган җир участогында урнаштыру факты ачыкланган очракта, вазыйфаи зат тикшерү тәмамланган көннән башлап биш эш көненнән дә соңга калмыйча Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә, әлеге фактны раслый торган документларны теркәп, рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазе җибәрә. Рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазенең формасы, шулай ук рөхсәтсез төзелеш билгеләре булуын раслый торган документлар исемлеге шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләренә карата җир участогына хокук иясе тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.»;

2) 1.5.2 пунктның унберенче абзацында «муниципаль җир контроле органы» сүзләрен «юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата җир законнарын бозуны бетерү турында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1.5.2.2 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта күрсәтелгән йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән үзара бәйләнешсез контроль чаралары нәтиҗәләрен, шул исәптән планлы (рейд) караулар, тикшерүләр, тикшеренүләр, үлчәүләр, күзәтүләр нәтиҗәләрен муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары тарафыннан рәсмиләштерү тәртибе Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.»;

4) 1.5.2.2 пунктның унберенче һәм уникенче абзацлары үз көчен югалтуны танырга;

5) 1.5.3 пунктның унберенче абзацында «гражданнарга» сүзен төшереп калдырырга;

6) 2.5.3 пунктның өченче абзацында «граждан» сүзен төшереп калдырырга;

7) 2.7 пунктның икенче абзацын «мәҗбүри таләпләрне үтәүдә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында» сүзләреннән соң «(гражданнардан тыш)» сүзләре белән тулыландырырга;

8) 3 нче таблицаның «Мәҗбүри таләпләрнең формулировкасы» баганасында «Җир законнарын бозуны бетерү турында күрсәтмәне үтәү» графасын «Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата җир законнарын бозуны бетерү турында күрсәтмәләрне үтәү» графасына алмаштырырга;

9) 5 бүлекнең өченче абзацында «муниципаль җир контроле органы» сүзләрен «юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата җир законнарын бозуларны бетерү турында» сүзләренә алмаштырырга;

10) 5 бүлекнең дүртенче абзацын «күрсәтмәләр» сүзеннән соң «юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата җир законнарын бозуларны бетерү турында» сүзләре белән тулыландырырга;

11) 5.1.1.8 пунктка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- дүртенче абзацны «бозулар» сүзеннән соң «юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата» сүзләре белән тулыландырырга;

- бишенче абзацны түбәндәге эчтәлектәге икенче җөмлә белән тулыландырырга:

«Үткәрелгән планлы тикшерү нәтиҗәләре буенча, вазыйфаи зат тарафыннан капиталь төзелеш объектын җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән чикләүләре нигезендә мондый объектны урнаштыру рөхсәт ителми торган җир участогында урнаштыру факты ачыкланган очракта, вазыйфаи зат тикшерү тәмамланган көннән башлап биш эш көненнән дә соңга калмыйча Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә, әлеге фактны раслый торган документларны теркәп, рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазе җибәрә. Рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазенең формасы, шулай ук рөхсәтсез төзелеш билгеләре булуын раслый торган документлар исемлеге шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләренә карата җир участогына хокук иясе тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.»;

12) 5.1.2.3 пунктның унынчы абзацында «гражданга» сүзен төшереп калдырырга;

13) түбәндәге эчтәлектәге 5.1.2.6 пункт белән тулыландырырга:

«5.1.2.6. Үткәрелгән планлы тикшерү нәтиҗәләре буенча, вазыйфаи зат тарафыннан капиталь төзелеш объектын җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән чикләүләре нигезендә мондый объектны урнаштыру рөхсәт ителми торган җир участогында урнаштыру факты ачыкланган очракта, вазыйфаи зат тикшерү тәмамланган көннән башлап биш эш көненнән дә соңга калмыйча Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә, әлеге фактны раслый торган документларны теркәп, рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазе җибәрә. Рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазенең формасы, шулай ук рөхсәтсез төзелеш билгеләре булуын раслый торган документлар исемлеге шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләренә карата җир участогына хокук иясе тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.»;

14) 5.2.1.6 пунктка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- икенче абзацны «законнар» сүзеннән соң «юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата» сүзләре белән тулылындырыга;

- түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«Үткәрелгән планлы тикшерү нәтиҗәләре буенча, вазыйфаи зат тарафыннан капиталь төзелеш объектын җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән чикләүләре нигезендә мондый объектны урнаштыру рөхсәт ителми торган җир участогында урнаштыру факты ачыкланган очракта, вазыйфаи зат тикшерү тәмамланган көннән башлап биш эш көненнән дә соңга калмыйча Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә, әлеге фактны раслый торган документларны теркәп, рөхсәтсез

төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазе җибәрә. Рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазенең формасы, шулай ук рөхсәтсез төзелеш билгеләре булуын раслый торган документлар исемлеге шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләренә карата җир участогына хокук иясе тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.»;

15) 5.2.2.7 пунктның өченче абзацын «законнар» сүзеннән соң «юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата» сүзләре белән тулылындырыга;

16) түбәндәге эчтәлектәге 5.2.2.9 пункт белән тулыландырырга:

«5.2.2.9. Үткәрелгән планлы тикшерү нәтиҗәләре буенча, вазыйфаи зат тарафыннан капиталь төзелеш объектын җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән чикләүләре нигезендә мондый объектны урнаштыру рөхсәт ителми торган җир участогында урнаштыру факты ачыкланган очракта, вазыйфаи зат тикшерү тәмамланган көннән башлап биш эш көненнән дә соңга калмыйча Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә, әлеге фактны раслый торган документларны теркәп, рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазе җибәрә. Рөхсәтсез төзелеш ачыклану турында белдерү кәгазенең формасы, шулай ук рөхсәтсез төзелеш билгеләре булуын раслый торган документлар исемлеге шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләренә карата җир участогына хокук иясе тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.»;

17) 4 нче кушымтада «граждан» сүзен төшереп калдырырга;

18) 6 нчы кушымтада «Сораулар*» баганасында «Җир законнарын бозуны бетерү турында күрсәтмәләрне үтәү» графасын «Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата җир законнарын бозуны бетерү турында күрсәтмәләрне үтәү» графасына алмаштырырга»;

19) 7 нче кушымтаның Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен үтәүнең административ процедураларының (гамәлләренең) блок-схемасын «күрсәтмә» сүзеннән соң «юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата җир законнарын бозуларны бетерү турында» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (parvo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин